**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия турында» 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1229 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 10 мартындагы ПУ-209 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 7 сентябрендәге ПУ-800 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-152 номерлы, 2018 елның 26 маендагы ПУ-392 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге ПУ-844 номерлы, 2019 елның 21 февралендәге ПУ-140 номерлы, 2019 елның 21 августындагы ПУ-478 номерлы һәм 2020 елның 18 февралендәге ПУ-100 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия (алга таба – комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Ф.С. Габделганиевны чыгарырга;

б) Комиссия составына Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улын – Татарстан Республикасы икътисад министрын кертергә, аны Комиссия секретаре итеп расларга;

в) Комиссия әгъзасы Ә.С. Гобәйдуллинның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 04 март
№ ПУ-136